ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13 март 2018ел № 1296

Башкарма комитетның «2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлегенә ярдәм күрсәтү һәм үстерү» программасын раслау турында» 2016 елның 2 ноябрендәге 5770 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, шәһәр Уставының 41 маддәсе, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2013 елның 11 декабрендәге 7511 нче карары нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлегенә ярдәм күрсәтү һәм үстерү» программасын раслау турында» 2016 елның 2 ноябрендәге 5770 нче карарына (Башкарма комитетның 2017 елның 10 гыйнварындагы 15 нче, 2017 елның 6 мартындагы 1089 нчы, 2017 елның 7 апрелендәге 1987 нче, 2017 елның 4 маендагы 2783 нче карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 бүлекнең 8 юлында программаны финанслау күләме һәм чыганакларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | Финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыру еллары | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2017 (мең сум) | 2018 (мең сум) | 2019 (мең сум) | Тормышка ашыру елында барлыгы (мең сум) |
| | Муниципаль бюджет | 7397,018 | 150 | 150 | 7697,018 |
| | Федераль бюджет | 22666,03174 | - | - | 22666,03174 |
| | Республика бюджеты | 38593,5135 | - | - | 38593,5135 |
| | Башка чыганаклар | - | - | - | - |
| | Барлыгы | 68656,56324 | 150 | 150 | 68956,56324 |

2) 5 бүлекнең 2 бурычын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2 бурыч. Производствоны яңадан технологик җиһазландыруга һәм хезмәт житештерүчәнлеген күтәрүгә ярдәм күрсәтү | | | | | | | | | | | |
| Җиһазлар лизингын үстерү: кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының җиһазлар лизингы («ЛИЗИНГ-ГРАНТ») | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе | 2017 | Дәүләт ярдәме күрсәтелгән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының саны, берәмлек | - | 34 шуның:<br>13 (федераль бюджет хисабына)<br>21 (республика бюджеты хисабына) | - | - | 58759,54524 шуның:<br>21741,03174 (федераль бюджет)<br>37018,5135 (республика бюджеты) | | | Яңа производстволар ачу һәм гамәлдәге производстволарны үстерү, булдырылган эш урыннары санын арттыру |
| | | | Дәүләт ярдәме күрсәтелгән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан яңа булдырылган эш урыннарының саны (яңа теркәлгән шәхси эшмәкәрләрне кертеп), берәмлек | - | 96 шуның:<br>35 (федераль бюджет хисабына)<br>61 (республика бюджеты хисабына) | - | - | | | | |
| Социаль эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе | 2017 | Дәүләт ярдәме күрсәтелгән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының саны, берәмлек | - | 5 шуның:<br>2 (федераль бюджет хисабына)<br>3 (республика бюджеты | - | - | 2500,0 шуның:<br>925,0 (федераль бюджет)<br>1575,0 (республика бюджеты) | | | Яңа производстволар ачу, эшчәнлеген социаль юнәлештә гамәлгә ашыручы предприятиеләрдә булды |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | хисабына) | | | | | | рылган эш урынннары санын арттыру |
| | | | Дәүләт ярдәме күрсәтелгән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан яңа булдырылган эш урыннарының саны (яңа теркәлгән шәхси эшмәкәрләрне кертеп), берәмлек | - | 2 шуның:<br>1 (федераль бюджет хисабына)<br>1 (республика бюджеты хисабына) | - | - | | | | |
| Эшмәкәрләргә республика һәм федераль ярдәм күрсәтү программалары буенча конкурсларда катнашуда ярдәм күрсәтү | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе | 2017-2019 еллар | Консультация бирелгән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының саны, берәмлек | 1150 | 1050 | 1250 | 1400 | - | - | - | Яңа производстволар ачу, булдырылган эш урыннары санын арттыру, салым чигерүләрен арттыру |

3) 5 бүлекнең йомгаклау юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Программа буенча барлыгы:<br>Федераль бюджет<br>Республика бюджеты<br>Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 68656,56324<br>22666,03174<br>38593,5135<br>7397,018 | 150,0<br>-<br>-<br>150,0 | 150,0<br>-<br>-<br>150,0 | |

4) 6 бүлекне кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә «2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлегенә ярдәм күрсәтү һәм үстерү» муниципаль программасы чараларын финанслауны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының «Гомумдәүләткә караган башка мәсьәләләр» 01.13, «Милли икътисад өлкәсендәге башка

мәсьәләләр» 04.12 бүлекләрендә (бүлекчәләрендә) каралган акчалар хисабына 68956,56324 мең сум: 2017 ел – 68656,56324 мең сум, 2018 ел – 150 мең сум, 2019 ел – 150 мең сум күләмендә тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2018 елның 13 мартындагы
1296 нчы карарына
кушымта

6 бүлек. Муниципаль программаны ресурслар белән тәэмин итү

| Чыгымнарның чыганаклары һәм юнәлешләре | Финанслау күләме, мең сум | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Барлыгы | шул исәптән еллар буенча | | |
| | | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел |
| Федераль бюджет | 22666,03174 | 22666,03174 | - | - |
| Республика бюджеты | 38593,5135 | 38593,5135 | | |
| Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 7697,018 | 7397,018 | 150,0 | 150,0 |
| Барлыгы | 68956,56324 | 68656,56324 | 150,0 | 150,0 |

Җирле бюджет акчаларының бер өлеше сәнәгать паркларын һәм мәйданчыкларын үстерүгә юллана. Шәһәр бюджетыннан субсидия бирү тәртибе турында нигезнамә Башкарма комитет карары белән раслана. Сәнәгать паркларына субсидия бирү кече һәм урта эшмәкәрлек производстволары нәтиҗәлелеген күтәрү өчен шартлар тудыра.

Федераль һәм республика бюджетлары акчалары түбәндәге программа чараларын тормышка ашыруга юллана: җиһазлар лизингын үстерү: кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары чыгымнарын субсидияләү («Лизинг-грант») һәм социаль эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү.

Җиһазлар лизингын үстерү: кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары чыгымнарын субсидияләүгә («Лизинг-грант») дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын сайлап алу тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 19 июнендәге 416 нчы карары белән расланган.

Яр Чаллы моношәһәренең җиһазлар лизингын һәм социаль эшмәкәрлекне үстерү чаралары кысаларында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын сайлап алу һәм субсидияләр рәвешендә ярдәм күрсәтү тәртибе Башкарма комитетның 2017 елның 24 маендагы 3178 нче карары белән расланган.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова